| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

**2018 елның 27 сентябре** **№ 26**

**Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Мөэмин-Каратай авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә,2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратайавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
«2019 елда Мөэмин-Каратай авыл җирлеге чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән һәр граждандан 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
Урамнарны яктыртуны карап тоту;
авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
« Әйе Юк».

2. Әлеге карарны Мөэмин-Каратай авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре»

бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Мөэмин-Каратай авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе Ә.А.Ханнанова